ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

25.11.2024　　　д. им. М. Вахитова　　　12

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004нче елның 28нче июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 07 декабрендә 12 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча: М.Вахитов исемендәге авыл, Үзәк урам, 24 йорт, авыл клубы бинасы ТР Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авыл халкына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Мулланур Вахитов исемендәге авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау

«ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК»

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Ф. Р. Кәримов